

А. МАЛИНСКАЯ

БЕЗНЕҢ Әдәмек

А. МАЛИНСКАЯ

БЕЗНЕҢ Адилек



К. Г. Котдусова тәрҗемәсе

ТАТКНИГОИЗДАТ
ЯШЬЛӘР-БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ РЕДАКЦИЯСЕ
КАЗАН 1957

* * *

Редакторы
Р. Т. ВӘЛИЕВА

Тышлык художнигы
И. К. КОЛМОГОРЦЕВА

Ю. КОРОВИН
рәсемнәре

* * *

МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН

А. МАЛИНСКАЯ

НАШ АДАМЕК

(на татарском языке)

Художество редакторы *Ә. Е. Дьячкова*
Техник редакторы *З. А. Ибраһимова*
Корректоры *С. В. Насыйбуллина*

Наборга бирелде 18|IV-1956 ел. Басарга кул куелды 19|X-1957 ел.
Кәгазь форматы 60 $\times$ 92$^1/_8$. Учет-идз. таб. 2,35 Басма табак 4.
Табакта 44.000 хәреф. Заказ № 0157. Тираж 15000. Бәясе 1 сум 05 тиен.

ТАССР Культура Министрлыгының Татполиграф типографиясе.
Казан, Миславский ур., йорт № 9.



АДАМЕКНЫҢ ТУУЫ

Иң элек мин сезгә бер өй турында сөйлим. Урманда зур-зур агачлар арасында кечкенә генә бер өй бар. Аңың кызыл чирәп түбәсе куе үлән эченнән пешкән җир җиләгесыман булып күренеп тора.

Ул өйдә хатыны Адамова белән урман каравылчысы Адам тора.

Һәр көн иртә белән урман каравылчысы мылтыгын алып урманга чыга. Ә урманда аның эше дөнья кадәр. Ул, агачлар исәннәрме икән, дип карый-карый имәннән чыршыга, чыршыдан наратка бара. Урман каравылчысының эше шундый инде аның — урмандагы агачларны карау!

Урман каравылчысы Адамның башка эшләре дә бар: менә миләш чыпчыгының оясын җил чак кына очыртып китмәгән, ул аны рәтләп куя, я мылтык атып усал карчыганы куа, я бөтен урманны яңгыратып кычкырган күкене тыңлап тора.



Әмма нәрсә генә эшләсә дә, урман каравылчысы Адам һәрвакыт бернәрсә турында уйлый: „Эх, безнең улыбыз, я кызыбыз булса иде! Улым минем белән урманга йөрер иде. Алма бакчасындагы алмагачларның төпләрен йомшартырга булышыр иде. Бөтен эштә булышчы булыр иде!“

Урман каравылчысы Адам урманда йөргән арада аның хатыны Адамова өй эшләрен карый: ашарга пешерә, кер юа, өй җыештыра. Һәм ни генә эшләсә дә, ул да гел шул бернәрсә турында уйлый: „Безнең кызыбыз, я улыбыз булса иде! Кызыбыз миңа ашка кишер чистартырга булышыр иде. Бергәләп бакчадагы түтәлләргә су сибәр идек. Кер юганда кулъяулыкларын сыгып куяр иде. Нинди әйбәт булыр иде!“



Ләкин бүген урман каравылчысы Адамның кәефе гадәттәгечә түгел. Урманга барып җитәргә дә өлгермәде, аның өенә кайтасы килә башлады.

Нәрсәгә генә тотынмасын, эшли алмый, бер эшкә дә кулы бармый аның.

Нәкъ менә кемдер аны ашыктырып тора төсле: „Өеңә кайт, Адам! Урмандагы бөтен эшеңне ташла да өеңә кайт, Адам!“— дип әйтә кебек.

Урман каравылчысы тиз генә өенә кайтып китә.

Менә ул чирәп түбәле кечкенә өенә якынлаша. Ерактан ук күзе белән хатыны Адамованы эзли башлый. Ник ул бакчада да, баскычта да күренми икән?

Менә Адам өенә кайтып та житә... Тагын бер атлый да кухняга керә. Кухнядан бүлмәгә үтә...

Һәм бүлмәдә нәрсә күрә дип уйлыйсыз? Бишек! Ә бишектә...

— Кечкентәй-тупылдык! — ди аңа хатыны Адамова. — Улкаебыз!


— Улкаебыз! — ди урман каравылчысы шатланып. — Адамек!

— Безнең Адамек! — ди аның хатыны, һәм алар бишектә тәмле итеп йоклап яткан нәни малай өстенә иеләләр.

Ә тәрәзәдән якты кояш нуры сибелә, черкелдәшә-черкелдәшә кошлар сайрый, яшел агач башларын жил тибрәтә. Урман каравылчысы Адам белән аның хатыны: „Безнең өебездә кечкентәй-тупылдык Адамек туганга бар да шатланалар“, — дип уйлыйлар.



ӘНИСЕ АДАМЕКНЫ НИГӘ АЧУЛАНДЫ



Вакыт бик тиз үтә. Әтисе белән әнисе әйләнеп карарга да өлгермиләр, Адамек инде йөгереп йөри һәм сөйләшә дә башлый.

Менә хәзер дә: кояш инде күптән агачлар артыннан күтәрелде, әтисе урманга китеп барды, ә Адамек уянды гына әле. Ул тиз генә кроватьтан идәнгә сикереп төште дә кухняга йөгереп чыкты.

Анда плита янында әнисе басып тора иде. Ә плита өстендә кечкенә генә кастрюля тора. Кастрюляда тәмле ис чыгарып быгырдый-быгырдый нәрсәдер кайный.

Адамекның кинәт ашыйсы килеп китте. Ул әнисенең итәгеннән тартты да кычкырып җибәрде:

— Әни, ашарга бир! Ашыйсым килә!

Ләкин, нәрсә инде бу? Әнисе Адамекка карамый да.

Адамек яңадан кычкырып җибәрде:

— Әни, ашарга бир! Минем ашыйсым килә!

Ә әнисе һаман бу кечкентәй-тупылдыкка әйләнеп тә карамый, аның монда икәнен күрми дә диярсең. Аның тавышын ишетмиме икән әллә?

Адамек бөтен көченә акыра башлады:

— Әни, ашыйсым килә! Миңа ашарга бир!

Менә гаҗәп! Әнисе аны танымый да. Ул Адамекка карый да ят тавыш белән:

— Белмим: бу кычкырган малай кем соң? Мондый малайны мин беренче тапкыр күрәм, — ди.

Адамек аны ышандырмакчы була:

— Мин ич! Синең улың! Адамек! Минем ашыйсым килә! — ди.

Ләкин юкка гына. Әнисе ачуланган ахрысы.

— Юк, юк, син Адамек түгел! — ди ул. — Чыгып кит бездән!

Әнисе Адамекны кухнядан чыгарып җибәрә дә ишекне яба. Нәрсә эшләсен инде хәзер бу малай?

Ул бакчага барып скамьяга утыра да үксеп-үксеп еларга тотына: „У-у, әни мине яратмый! Әни минем белән сөйләшми...“

Адамек бик каты акырып елый, аның тавышы хәтта урман эчендәге аланда да ишетелә. Ә анда бу вакытта Адамекның этисе кечкенә чыршы үсентеләре утырта. Ул үсентеләр дә әле Адамек кебек кечкенә генә булалар.

„Нигә безнең Адамек болай кычкыра икән? — дип уйлый этисе. — Корт чакты микән әллә? Кайтып карап килим әле...“

Әти кеше ул бик тиз йөри шул. Менә ул бакчага кайтып та җитә. Анда нәрсә күрә дисез: кечкентәй-тупылдык скамьяда утыра, ә күзләреннән тамчы-тамчы яшьләр тәгәри.

— Ни булды сиңа, Адамек? — дип сорый этисе.

Аңа җавап итеп Адамек тагын да катырак елый башлый.

— Әй-яй-яй, Адамек! — ди этисе, эшне сизеп алып. — Син берәр ярамаган нәрсә эшләгәнсең ахры?



— Юк, — ди Адамек, үкси-үкси, — мин бернинди дә ярамаган эш эшләмәдем, ашарга гына сорадым.

Һәм ул этисенә барысын да сөйләп бирә.

— Менә нәрсә, улым, — ди аңа этисе: — син елавыңнан тукта да уйлап кара әле: әниең нигә ачуланды икән соң сиңа? Нинди сүзне оныткансың икән син?

Адамек аптырап китә, хәтта елавыннан да шундук туктый. Чыннан да, әнисе ник ачуланды икән соң аңа? Нинди сүз әйтергә онытыкан икән Адамек?

Әтисе аңа ярдәмгә килә:

— Шулай, „бир“, „ашыйсым килә“ дип кенә әйтергә ярыймыни? Я әле,

Адамек, исеңә төшер әле, нинди бик кирәкле сүзне онытқансың икән?

— Исемә төште! — дип кычкыра Адамек шатланып һәм шундук әнисе янына кухняга йөгерә.

Ә хәзер сез дә яхшылап тыңлап торыгыз! Ул сүз сезнең дә колак яныгыздан гына үтеп китмәсен!




— Әнием! — ди Адамек әкрен генә, әнисенең алъяпкыч итәгеннән тартып. — Миңа ашарга бир әле, зинһар, әнием!

Шулай диюгә әнисе Адамекка елмаеп карый һәм:

— Ачыккан икән безнең Адамек! Улыбызның ашыйсы килгән икән! Әйдә, ашатыйм әле үзеңне, кечкентәем-тупылдыгым минем! — ди.

Шуннан соң әнисе аңа кружка тутырып әллә сөт, әллә какао, әллә кофе салып бирә. Кыскасы, нindидер бик тәмле дә, файдалы да нәрсә була ул. Әйе шул, файдалы нәрсә! Шуны эчкәч, Адамек яхшы ук үсеп тә, акыллыланып та китә.



АДАМЕК АШЫКМЫЙ

Карагыз әле, менә нинди булып үсте хәзер кечкентәй-тупылдык!

Ул инде ала сыерны карап ашатып йөри. Кайвакыт әнисенә савыт-саба сөртергә булыша. Ә бер вакытны урманнан бер кружка пешкән кура җиләге җыеп кайтты.

Тик менә Адамекның яратмаган бер эше бар — бу турыда әйтергә дә оят инде: ул үзе киенергә яратмый.

— Адамек, — ди аңа әнисе иртәләрен, — әйдә, төймәләреңне каптырырга өйрәник.

— Иртәгә өйрәнербез, — ди Адамек, һәм аның төймәләрен әнисе үзе каптыра.

— Адамек, — ди әнисе тагын икенче көнне иртә белән, — әйдә, оекларыңны кияргә өйрәнәсең киләме?

— Иртәгә өйрәнербез, — ди Адамек, һәм әнисе аның оекларын, уң аягыныкын да, сул аягыныкын да, үзе кидерә.

— Адамек, — ди әнисе өченче көнне иртә белән яңадан, — курткаңны үзең киеп кара әле...

Әмма Адамек тагын иртәгәгә калдыра. Әнисе аңа оекларын, курткасын һәм башка киемнәрен тагын үзе кидерә.

Адамек һаман, иртәгә дә, иртәгә, ди! Шулай итеп, пәнҗешәмбе көн дә килеп җитә.

Ә ул көнне менә нәрсә булды.

Пәнҗешәмбе көнне урман каравылчысы Адам яшь каен үсентеләре алып кайтырга питомникка барырга тиеш иде. Хатыны Адамова да аның белән китте. Алар өйдән иртүк чыгып киттеләр. Адамек йоклый иде әле.

Кояш чыккач, яктыргач, Адамек үзенең кроватенда әйләнгәләп ятты-ятты да уянып китте.

Уянды да:

— Әни! Әти! — дип, аларны чакыра башлады.

Ә өйдә тып-тын. Әнисе дә юк. Әтисе дә юк. Беркем дә юк.

Шулай да Адамек курыкмый. Ә нәрсәдән куркырга аңа? Әтисе белән әнисе тиздән кайтырлар, кайткач улларын мактарлар да әле: „Менә нинди акыллы безнең улыбыз Адамек! Бернәрсәдән дә курыкмый!“ — диярләр.



Адамек үзенең кроватенда уйный башлады. Менә ул одеялдан палатка корып куйды. Үзе палатка эченә керде дә калач кебек бөгәрләнеп ятты: нәкъ экәм-төкәм шикелле!

Юк, экәм-төкәм булып уйнаганчы эт булып уйнау әйбәтрәк. Ә палатка эт оясы була. Көчек шундый ояда тора ич.

Ә әнисе һаман кайтмый да кайтмый. Нигә шулай озак кайтмый соң ул?

— Торырга вакыт, — ди Адамек үзенә-үзе һәм кроватьтан идәнгә сикереп төшә.



Әй-яй-яй, эчке күлмәктән генә бик салкын икән! Тизрәк киенергә кирәк!

Адамек урындыктан курткасын ала. Аны алай да, болай да әйләндергәләп карый да:

— Штандыр әле бу. Киим әле мин моны! — ди.

Адамек бер аягын бер җиңгә, икенче аягын икенче җиңгә тыга.

Никтер штанны бер дә киеп булмый. Ул һич кичәге шикелле түгел. Кечкенә. Кыска. Бер төн эчендә Адамек шулай үскән микәнни соң?

„Ә хәзер куртканы кияргә кирәк“, — дип уйлый Адамек һәм урындыкта яткан штанын ала.

Бер кулын бер балагына, икенче кулын икенче балагына тыга.

Ә төймәләре кайда соң? Кичә бик күп иде ич алар, ә бүген кая киткәннәр икән?

Менә бәла! Адамек бернәрсә дә эшли алмый, аның бер эше дә барып чыкмый...


Әтисе белән әнисе дә кайтып җитәләр. Алар үзләренең Адамекларын, үзләренең кечкентәйләрен менә нинди хәлдә күрәләр!

— Бүген курткам начар минем,—дип зарлана Адамек әнисенә.—Төймәләрен каптырып булмый!

— Нинди куртка булсын ул? Штан ич бу, Адамек!—ди әнисе көлеп.

Куртка урынына штан, штан урынына куртка—менә ничек киенгән безнең Адамек!

Зарар юк әйдә! Бу элек булган эш инде. Хәзер Адамек киенергә өйрәнеп кенә калмады, ә тагын бернәрсәне бик яхшы белде: бүген эшләргә мөмкин булган эшне иртәгәгә калдырырга ярамый икән!





АДАМЕК БЕЛӘН БРОК АУГА БАРАЛАР

Бүген Адамек Брок исемле көчек белән уйный.

— Брок, — ди Адамек, — әйдә урманга барып кайтабыз. Җәнлекләр аударбыз. Барасыңмы?

Көчек койрыгын болгый — барасы килә, димәк.

Менә алар сукмак буйлап туп-туры урманга киттеләр. Алдан Адамек, аның артыннан Брок бара.

Адамек чын аучылар шикелле, бер генә ботак та чытырдамаслык итеп, сагаеп кына атлый. Брок та үзен ау этләре кебек тота: иснәнә-иснәнә бара.

Кинәт — тукта! Адамек туктап кала. Сукмак өстендә, кояш иң нык кыздырган җирдә... Белегез әле, нәрсә ята икән?

— Брок, елан! — ди Адамек пышылдап. — Кара әле, нинди...

Ә Брок — ул еланны әлегрәк тә күреп алгандыр әле — туктады да бар тавышына өрә башлады: „Әх, нинди кызыл! Нинди озын!“

— Зарар юк, Брок, — ди Адамек. — Ул бездән кача алмас. Без аны тотып алырбыз.

Тотарга була да, тик менә

ничек тотарга? Андый нәрсәгә кулыңны тидерергә дә куркыныч...

— Бездән ычкына алмас! Без аны койма белән әйләндереп алырбыз. Биек-биек койма белән!

Көчек тә еланны койма белән әйләндереп алуга шатлана ахры, койрыгын болгый!

Башта бер таш янына икенчесен, бер таш янына икенчесен куясың... Ә аннан соң берсенең өстенә берсен, берсенең өстенә берсен өясең...

Менә стена әзер дә булды! Хәзер түбәсен ябасы гына калды. Моннан елан беркая да китә алмый инде: ишеге дә, тәрә-



зәләре дә, морҗасы да юк!

Әти белән әни тизрәк кайтсыннар иде. Адамек белән Брокның нинди елан тотканын күрсеннәр әле.

Менә дүртәүләп еланны карарга киләләр. Иң алдан Адамек йөгерә. Адамек артыннан — Брок. Брок артыннан — әтисе белән әнисе.

— Карыйк әле, нииндирәк аучы икән безнең Адамек! — ди әтисе.

— Менә! — дип кычкыра Адамек һәм өй түбәсен ачып җибәрә. — Барыгыз да карагыз.

Ә анда карар нәрсә дә юк: койма эче буп-буш. Еланның эзе дә калмаган.

— Брок, — ди Адамек гаҗәпләнеп, — кая киткән икән ул?
Брок та аптырап кала, ул шулкадәр гаҗәпләнә, хәтта койрыгын болгаудан да туктый.

— Адамек, — ди әнисе, — җирдәге тишекне күрәсеңме? Еланың шунда кереп киткән синең. Яңгыр суалчаны булган ул, ә суалчаннар һәрвакыт җир эчендә яшиләр...

Шулай да кызык инде бу Адамек белән Брок: суалчанны елан дип уйлаганнар!





ӘНИНЕҢ БӘЙЛӘВЕ

Адамек үләнгә сузылып яткан, ә аның янында мәче Мыр-мырау йөри. Шунда ук әнисенең бәйли торган оегы ята, ә оектан йомгакка озын, бик озын җеп сузылган.

— Әни бәйләвенә тимәскә кушты,— ди Адамек,— без аңа тимибез. Ярыймы, Мыр-мырау?

Мыр-мырау әкрен генә койрыгын селкетә һәм Адамекка күз кыса: тияргә кушмагач, тимибез инде, янәсе!

Ничек тимәссең инде? Җепне әз генә тарттыңмы — үлән өстендәге йомгак үзеннән-үзе тәгәри дә китә. Җитмәсә төрле якка тәгәри! Туп-туры Мыр-мырауга таба килә...

Мыр-мырау түзеп тора алмый: ул йомгакны тәгәрәтеп җибәрә, элек бер аягы белән, аннары икенчесе белән, элек берсе белән, аннары икенчесе белән...

Менә йомгак куак төбенә тәгәрәп китә, бәйләүнең бер энәсе суырылып чыга, оекта буш элмәкләр тезелеп кала, ә алардан җеп, тере әйбер кебек, аска таба шуыша да шуыша.

Адамек белән Брок икесе дә күңелсезләнәләр.

— Ах, Мыр-мырау,— дип пышылдый Адамек,— әни ачуланыр инде!

Ә Мыр-мырау хәйләкәр! Ул кояшка сузылып ята да күзләрен кыскалый: минем ни катнашым бар, янәсе. Мин гел йоклап яттым, бернәрсә дә күрмәдем, янәсе.

Шуннан соң Адамек та тиз генә йөзтүбән капланып ята да күзләрен йома. Куак төбендәге йомгакны да, үлән арасында яткан энәне дә, оектагы буш элмәкләрне дә Мыр-мырау белән аларның белгәннәре дә, күргәннәре дә юк, янәсе.

— Адамек,— ди энисе,— ни өчен минем бәйли торган оегыма кагылдың?

Менә бит нинди ул! Килеп җитәргә дә өлгермәде, оекка карау белән барысын сизеп алды.

— Без кагылмадык,— ди Адамек.

Ә Мыр-мырау койрыгының очын гына селкетеп, бер күз кырые белән генә Адамекның энисенә карап ала: янәсе, уятмагыз мине, мин йоклыйм, мин берни дә белмим.

Хәйләкәр дә соң бу Мыр-мырау! Йомгакны бергә тәгәрәттеләр, ә энисе белән сөйләшергә Адамекның үзенә генә туры килә.

— Без тимәдек аңа,— ди Адамек яңадан.— Йомгак үзе тәгәрәп китте. Оектагы энәләр үзләре төштеләр. Элмәкләр дә үзләре сүтелеп китте...

Сез ничек уйлыйсыз, энисе Адамек белән Мыр-мырауга ышандымы, юкмы? Юк, ул аларга бик, бик үпкәләде.

— Ялганлау начар! — диде ул Адамекка һәм аның белән башка сөйләшмәс булды.

Адамек бик оялды. Шуннан бирле аның беркайчан да ялган сөйләгәне юк.



АДАМЕК НӘРСӘДӘН КУРКА





Сез Адамекны караңгыдан курка дип уйлыйсызмы әллә?

Юк ла! Адамек — акыллы малай ул. Караңгыдан курыкмый. Тик менә энисе таска салкын су салдымы, Адамек шунда ук бүлмәдән йөгереп чыгып китә.

Менә хәзер дә сары тәпиле каз бәбкәләре су буенда үлән чүпләп йөриләр, ә Адамек энисе белән яр башында тора.

— Казлар, ак казлар,— ди энисе,— нәрсә эшләргә инде? Адамек су коеныргга теләми! Судан курка! Су салкын, ди! Казлар, казлар, сез моңа ни дисез?

Ә казлар ни дисеннәр инде. Буада су җып-җылы — көн буена кояшта җылынып торган. Казлар Адамекка карыйлар да үзара сөйләшәләр, каңгылдашалар.

— Ишетәсеңме, Адамек,— ди энисе,— казлар сине үртиләр...

Адамек иренен турсайта: үртәгәнне яратмый ул.

— Тыңлап кына кара әле, казлар ни диләр бит,— дип дәвам итә энисе.





Ай, бигрәк кызык икән—
Аңа су суык икән!
Кыйгак-кыйгак, кыйгак-кыйгак,
Ай, бигрәк кызык икән!

— Ничек үртәшергә икәнне күрсәтәм хәзер мин аларга,— ди Адамек ачуланып.—Мин аларның барысын да тотып алам хәзер...

Адамек казлар артыннан йөгерә башлый. Ә казлар Адамектан качалар. Адамек казлар артыннан йөгерә, ә казлар канатларын кагып алалар да, туп-туры суга төшеп, йөзеп тә китәләр.

Үзләре йөзәләр, үзләре су буен яңгыратып каңгылдашалар:

Кыйгак-кыйгак, кыйгак-кыйгак,
Аңа су суык икән!

Менә бит нинди ул казлар!

Адамек моңа түзеп тора алмый.

— Карагыз, казлар,— дип кычкыра ул,— мин салкын судан куркаммыни?

Үз күзләреңә үзең ышанмассың: Адамек „һоп“ итеп суга барып та керде!

Әнисе дөрес әйтә икән: су җылы, рәхәт! Төбендәге ташларга кадәр күренеп тора — шундый тонык.

— Адамек,— ди әнисе,— мунчала ал да терсәкләреңне, тезләреңне, башларыңны, муеныңны, аякларыңны яхшылап ышкы...


Адамек терсәкләрен, тезләрен, муенын, яңакларын ышкый-ышкый юа да ап-ак казлар шикелле ак, чиста малай була.

Хәзер инде казлар да аны:

Кыйгак-кыйгак, кыйгак-кыйгак,
Ай, бигрәк кызык икән!
Аңа су суык икән!
Кыйгак-кыйгак, кыйгак-кыйгак! —

дип үртәмәсләр.





УЕНЧЫКЛАРНЫ КЕМ ҖЫЕП КУЯ ИКӘН

Кич белән үзегез йокларга яткач, идән тулып анда-монда чәчелеп калган уенчыкларыгызны кем җыеп куя дип уйлыйсыз?

Әниегез, әбиегез яки апагыз җыя дисезме!

Юк, Адамек алай уйламый. Уенчыклар белән маташырга аның әнисенең вакыты юк.

Бу турыда ул Адамекка бер генә тапкыр әйтмәде инде.

Ләкин менә һәрвакыт шундый гаҗәп хәл була.

Адамек йокларга ятканда уенчыклар бүлмә тутырып чәчелеп яткан көе кала; ә иртән, Адамек уянганда, алар барысы бергә катыргы тартмада була. Кем җыеп куя соң аларны?

„Аларны һич тә әни җыеп куймый,—дип уйлый Адамек.— Аларны әкият китабында яшәүче кечкенә кеше җыеп куя. Көндез аны күреп булмый. Бөтен кеше йоклап беткәч, төнлә генә эшли ул. Шунда башлана да инде аның эше! Ул төн буе тырыша-тырыша эшләп, идән буйлап үрмәләп йөридер. Әле төрле төстәге шарларны җыеп тартмага тутыра, әле юллы-юллы зур тупны тартма янына тәгәрәтеп китерә, әле шакмакларны берсе өстенә берсен өя башлый торгандыр“. Бу кечкенә кеше таң атканчы эшли, ә иртә белән уенчыклар бар да үз урыннарында булалар, Адамек тагын аларны төрле җиргә таратып уйный ала.

Беркөнне кич әнисе Адамекка:

— Теләсәң нишлә, Адамек, бүген минем вакытым юк. Уенчыкларыңны үзең җый,—диде.



„Мин уенчыкларны җыеп тормам!—дип уйлый Адамек.— Аларны минем кечкенә кешем җыеп куяр әле“.

Һәм Адамек тыныч кына йокларга ята.

Хәерле иртә! Адамек уяна да иң элек уенчыклары янына килә. Ә тартма буш тора. Анда бернәрсә дә юк—шакмаклар да юк, шарлар да, яңа машинасы да юк.

Нәрсә эшләргә? Адамекның шарлар белән уйныйсы килә. Ул шарларын эзләп бик озак идән буенча мүкәләп йөри, соңгысын тик кич җиткәндә генә таба.


„Менә,—дип уйлый Адамек,—көн буе мин үземнең шарларымны эзләп йөрдем, ә уйнарга вакыт та калмады“.


Икенче көнне Адамек яңа йөк машинасы белән уйнамакчы булды. Адамек аны эзләргә тотынды: өстәл астын да, урындыклар астын да, шкаф астын да карады—бер кайда да юк! Йөк машинасы тик кич белән генә кровать астыннан табылды.

„Менә,—дип уйлады Адамек,—инде йокларга вакыт, йөк машинасы белән уйный да алмадым“.

Ә өченче көнне иртән Адамек үзенең юллы-юллы матур тубын эзләргә тотынды. Бакчадан да эзләде, чәчәк түтәлләре яныннан да эзләде—юк кына бит! Ә кич белән, Адамекның куллары-аяклары арыгач, туп үзе табылды. Өстәл астында яткан икән!

Хәзер Адамек кечкенә кешегә бүтән ышанмый инде һәм кичләрен уенчыкларын катыргы тартмага үзе җыеп куя. Кайвакытта аңа әнисе дә булыша.





АДАМЕК ГӨМБӘ ҖЫЯ

Карагыз әле, безнең Адамек кая барырга җыенган! Кулына кәрзин тоткан. Урманга гөмбәгә бара микәнни?

Гөмбәгә, гөмбәгә!

— Әни, мин кәрзин тутырып гөмбә алып кайтырмын! Тик акларын гына! — дип кычкыра ул бакчадан әнисенә.

— Каен гөмбәләре алып кайтсаң да ярый,— ди әнисе.—Тәмле гөмбә ул.

— Чыршы гөмбәсе дә әйбәт,— дип өстәп куя этисе.

Ә Брок аның артыннан өреп бара: валуй дигән гөмбә дә ярый, Адамек, ул да яхшы гөмбә,— ди, янәсе.

Адамек бик кызу бара. Нәкъ этисе шикелле.

Шәп тә инде урманда! Аяк асты йоп-йомшак, ямь-яшел мүк белән капланган, келәм шикелле кабарып тора. Ә агачлар, ботаклары белән бер-берсен кочаклаган шикелле үрелеп үскәннәр. Яфраклар арасында кошлар сикерешәләр, сайрыйлар, черкелдәшәләр.

Адамекның кәрзине буш әле; ул, аяк астына караудан бигрәк, агач башларын күзәтә.

Кинәт Адамек мүк арасында үсеп утырган бер гөмбәне күрә. Гөмбә дәшми-тынмый тик утыра. Үзе нык, юан, тик бик-бик кечкенә әле.

„Өзәргәме, юкмы? — дип уйлый Адамек. — Бигрәк кечкенәсең шул, гөмбәкәй. Үскәнеңне көтим әле!“ — ди ул һәм гөмбә янына муккә килеп утыра.

Ә мүк өстендә утырырга шундый йомшак, җайлы. Кинәт Адамекның күзләре үзләреннән-үзләре йомылалар һәм ул татлы йокыга тала.

Шул арада гөмбә үсә. Зурайганнан-зурая бара. Эшләпәсе кып-кызыл, ап-ак бөрчекләр төшкән, ә сап тирәләре челтәрләнеп тора. Менә гөмбә ичмасам!

— Менә гөмбә ичмасам! — ди Адамек күзен ачып. — Ак булмаса ни, аның каравы нинди зур, нинди матур! Кереп ят әле кәрзин эченә, гөмбә, әйдә өйгә киттек!



0157,—4

Адамек сукмак буйлап йөгерә. Бер гөмбәсе бар аның, ә икенчесенең кирәге дә юк — кәрзине туп-тулы.

Йөгереп өйгә кайтып җитә дә мактана башлый Адамек.

— Әти, әни, Брок! Карагыз әле, нинди гөмбә! Кыздырырга кирәк...— ди ул.

Әтисе белән әнисе гөмбәгә карыйлар да көләләр, ә Брок өрә дә өрә.

— Дөрес, Брок! — ди әтисе. — Гөмбәмени бу!


— Нигә гөмбә булмасын? — ди Адамек, үпкәләп. — Үзе зур, үзе матур...


— Урманда яхшы гөмбәләр дә бик күп, ә син агулы кызыл чебен гөмбәсе алып кайткансың! Андый гөмбәне кыздырмыйлар! Башка гөмбәләр юк идемени соң? — дип сорый әнисе.

— Ярый, зарар юк,— ди әтисе.— Иртәгә улыбыз тагын урманга барыр, безгә тик ак гөмбәләр генә алып кайтыр. Шулаймы, Адамек?

— Алып кайтырмын,— ди Адамек.

Ә үзе эченнән генә уйлый: „Хәзер инде урманда йокламам. Йоклап китмәс өчен чәнечкеләр өстенә утырырмын. Шулай итсәм бәлки кечкенә гөмбәдән чебен гөмбәсе түгел, ә чын ак гөмбә үсәр“.





АДАМЕК НИЧЕК ИТЕП БРИГАДНИКЛАРГА БУЛЫШТЫ

Адамек бүлмәдә йөгереп уйнап йөри, ә үзе әтисе белән әнисенең сөйләшкәнен тыңлый.

— Килделәрдәмени инде?—дип сорый әнисе.

— Килделәр,—ди әтисе.

— Ничә машина?—дип сорый әнисе.

— Ике машина,—ди әтисе.—Икесе дә туп-тулы.

— Прагаданмы?—дип сорый әнисе яңадан.


— Прагадан, Прагадан!—ди әтисе һәм:—Аларның ничек эшләүләрен күрсәң иде син! Мин дә шунда йөгерәм. Аларга булышырмын,—дип өстәп куя.

— Әти,—дип сорый Адамек,—кем килде?

— Прагадан бригадниклар килде,—дип аңлата әтисе.—Алар якшәмбе көнгә урманда эшләргә килделәр. Хәзер Чехословакиядә республика төзү эшенә һәркем булышырга тырыша.

— Мин дә булышырга телим,—ди Адамек.—Мине дә алып бар әле, мин бригадниклар белән эшләрмен.

— Кая инде сиңа анда барырга, Адамек,—ди әтисе.—Син кечкенә әле.



Ләкин Адамекның Прагадан килгән бригадниклар белән шундый эшлисе килә һәм ул үзен дә алып баруын әтисеннән шундый ялынып сорый, ахырда әнисе дә аны яклый башлый:

— Алып бар инде шуны. Син бит Адамекның тизрәк үсеп җитеп, бригадник булуын теләгән идең? — ди ул.

— Киттек алайса, — ди әтисе.

Алар китәләр.

Менә аланга да килеп җитәләр. Монда никадәр кеше! Һәркайсының кулында тимер ыргаклы зур таяк.

Үзагачын кимереп агачны корытучы кабык кондызлары үрчемәсен өчен киселгән агачның кайрысын ыргак белән куптарырга кирәк.

— Сезгә булышчы алып киләм! — дип кычкыра әтисе еракта ук, кечкенә Адамекка күрсәтеп.

— Бик яхшы булышчы бу,—ди бер бригадник.—Менә сиңа ыргак. Эшли башла, кечкентәй.

Тик ыргак шундый зур, шундый авыр, Адамек аны берничек тә күтәрә алмый. Ул гарьлегеннән елап җибәрергә җитә. Уйлап кына кара—үзе булышырга килде, үзе ыргакны да күтәрә алмый бит! „Менә сиңа Адамек! Менә сиңа булышчы!“—дип көлә башларлар инде.

Шул вакыт иң яшь бер бригадник:

— Эссе дә соң! Эх, бер генә йотым су булса!—дип куя.

— Мин сезгә кувшин тутырып алып киләм,—ди Адамек.

— Син кечкенә әле, кая сиңа!—ди бригадник.

Ләкин Адамек өйләренә таба йөгерә инде. Юлны табуы бер дә кыен түгел—әнә яшел яфраклар арасыннан кызыл чирәп түбә күренеп тора. Адамек кувшинга су тутыра да яңадан бригадниклар эшләгән җиргә, аланга йөгерә.

— Менә,—ди Адамек,—рәхим итеп эчегез!—Һәм ул теге эчәсе килгән яшь бригадникка кувшин белән сап-салкын чиста су бирә.



— Әй, Адамек! Әй, молодец! — дип Адамекны мактый яшь бригадник һәм иптәшләрен чакыра: — Кемнәрнең эчәсе килә, бирегә килегез! — ди.

Адамек көн буе алан белән өй арасында йөгереп йөри.



Өйдән ул су белән тулы кувшин алып китә, ә кире кайтканда кувшинында бер тамчы да су булмый, коп-коры була.

— Арымадыңмы, Адамек? — дип сорый әнисе.

— Арымадыңмы, Адамек? — дип сорый әтисе.

Адамек бик арый, ләкин ул бу турыда берәүгә дә әйтми, көн буе әле туп-тулы, әле буп-буш кувшин күтәреп өй белән алан арасында чабып йөри.

Ә кич булгач, Адамекның бөтенләй хәле беткәч, бригада эштән туктый. Шунда инде барысы да, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, Адамекка рәхмәт әйтергә, аны мактарга тотыналар:

— Рәхмәт, Адамек, син безгә бик нык ярдәм иттең! Мондый эсседә сусыз ничек эшләр идек без!—диләр.



Ә бригадникларның башлыгы:

—Яхшы эшләгәне өчен Адамекка бригадник исеме бирергә һәм аны менә бу значок белән бүләкләргә кирәк,—ди. Ул үзенең пиджагыннан кызыл, ак, зәңгәр тасмалы ал пыяла чәчәкне ала да Адамекның күлмәгенә кадап куя.


— Менә сиңа Адамек!—ди әтисе.—Үзе кечкенә генә, ә үзе яхшы эшләгән өчен бүләк тә алды инде.

— Ник кечкенә булыйм мин! — ди Адамек, значогын карый-карый. — Миңа биш яшь тулды инде!

Шуннан соң бригадниклар барысы да машинага утыралар.

— Хуш, Адамек! Хуш, бригадник! — дип кычкыралар алар, Адамек белән хушлашып.

Кызыл, ак, зәңгәр тасмалы ал пыяла чәчәкне Адамек әле хәзер дә саклый, һәм ул яхшы эшләгәне өчен алган бу беренче бүләге белән бик горурлана.



Бәясе 1 сум 05 тиен